| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05 апреля 2019г. № 1766

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы Иҗтимагый совет төзү турында» 2016 елның 10 августындагы 4150 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Уставының 42 маддәсе, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы Иҗтимагый совет төзү турында» 2016 елның 10 августындагы 4150 нче карарына (Башкарма комитетның 2017 елның 9 июнендәге 3533 нче, 2018 елның 29 декабрендәге 7886 нчы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы Иҗтимагый совет турында нигезнамәнең 9 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 4 пунктча белән тулыландырырга:

«4) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыру:

- коррупциягә каршы тору өлкәсендә сәясәтне тормышка ашыруда катнашу;
- коррупциягә каршы сәясәтне тормышка ашыруда катнашучы җирле үзидарә органнары, массакүләм мәгълүмат чаралары, оешмалар, шул исәптән иҗтимагый берләшмәләр белән үзара бәйләнештә булу;
- коррупциягә каршы дөньяга карашны коррупциягә каршы пропагандалау системасын формалаштыру, коррупциягә каршы торуга, коррупциягә каршы тору чараларын тормышка ашыруга иҗтимагый контрольне үстерүгә юнәлдерелгән гражданнар инициативаларын күрсәтү;
- җәмгыятьтә коррупциягә карата түзеп торгысыз мөнәсәбәт формалаштыру эшендә катнашу.»;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы мәдәният, мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча Иҗтимагый совет составын 1 нче кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 5 апрелендәге
1766 нчы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы мәдәният, мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча
Иҗтимагый совет составы

| Т/с | Ф.И.А.и. | Вазыйфасы |
|---|---|---|
| 1. | Зайцева Валентина Алексеевна | Иҗтимагый совет рәисе, педагогия хезмәте ветераны, «Россия Пенсионерлар берлеге» Бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәрендәге җирле бүлеге әгъзасы (килешенү буенча) |
| 2. | Манусова Валентина Николаевна | Иҗтимагый совет рәисе урынбасары, хезмәт ветераны (килешенү буенча) |
| 3. | Львова Роза Алексеевна | Иҗтимагый совет секретаре, педагогия хезмәте ветераны (килешенү буенча) |
| Иҗтимагый совет әгъзалары | | |
| 4. | Ипеева Райчка Дмитриевна | Яр Чаллы шәһәренең мактаулы гражданы (килешенү буенча) |
| 5. | Хәмидуллин Рафаэль Азат улы | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы карамагындагы Иҗтимагый яшьләр парламенты рәисе (килешенү буенча) |
| 6. | Жестков Эдуард Михайлович | «Әтиләр берлеге» Татарстан Республикасы региональ иҗтимагый оешмасы рәисе (килешенү буенча) |
| 7. | Миргалимова Мөслимә Гариф кызы | педагогия хезмәте ветераны (килешенү буенча) |
| 8. | Фәйрушин Әнәс Батыр улы | Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре (килешенү буенча) |
| 9. | Фәтхуллина Роза Гариф кызы | хезмәт ветераны (килешенү буенча). |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе — Г.К. Әхмәтова

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ